| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

28.12.2018 — № 1899-п

2019 елда халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы нигезендә һәм «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 17 декабрендәге 941 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 1 гыйнварыннан торак урыныннан файдаланган өчен түләүнең чик күләмен (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы буенча 2019 елга халык өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен расларга һәм гамәлгә кертергә. (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарны «Саба таннары» район газетасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад бүлеге башлыгы М.М. Баһмановка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов